Эчтәлек

Л.Ф.Шайдуллина

Яхшылык эшләргә ашыгыйк!....................................4
Ягез әле, этиләр! ……………………………………10
Сөмбелә бәйрәме. ……………………………………19

Ә.Х.Шиһапова

Әлифба әкиятләр илендә ……………………………25
Әдәпленең күлмәге сәдәпле, үзе күркәм гадәтле….37

М.М.Сафина

Туган авылым...      .......................................................46
Әлифба бәйрәме ..........................................................52

Ә.Х.Шиһапова

Батыр конкурсы ..........................................................63



Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы
Кәркәүч урта гомуми белем бирү мәктәбе

# Онытылмас мәктәп еллары

**(сыйныфтан тыш чаралар)**

**Кукмара**

**Авторлар:** Шайдуллина Л Ф., Шиһапова Ә. Х., Сафина М.М. Кәркәүч урта гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучылары

**Рецензентлар: Галиәхмәтова Гөлзилә Нәкыйповна**, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының мәгълүмати - методик үзәге әйдәп баручы белгече

**Саверьянова Зөлфия Илгизовна** Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының мәгълүмати - методик үзәге баш белгече

Сыйныфтан тыш чаралар 1- 4 сыйныф

Җыентыкта мәктәптә бәйрәмнәр, кичәләр уздырганда файдалану өчен сценарийлар, әдәби- музыкаль композицияләр тупланды.

**Онытылмас мәктәп еллары.** Мөгаллимнәргә, методистларга, тәрбиячеләргә методик кулланма булыр, дип ышанабыз.

**Редактор: Ахметзанов Илгиз Агмалович**, Кәркәүч урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры

**Конкурсның исемен табу**

Җиңгән команда тактага беркетелгән рәсемнәрнең баш хәрефләреннән сүз төзиләр

Һәм ул командага “Батыр” исеме бирелә.



Күп төрле
Яшелчәләр үстерде
Бездә нәрсәләр уңган-
Белегез табышмактан

**1 командага:**

- Җир астында җирән ат,
- Аның тиресе җиде кат.
- Суярсың да тунарсың,
- Тунаганда еларсың.



- Кыш киләсен ул белгән-
- Җәен җитмеш тун кигән.

**2 командага:**

- Җир астында алтын казык.



Чәчәге агачында

- Алмасы тамырында

**Кем күбрәк сүз төзи**

Карлыгач

Кар, карлы, кара, ач, ача, карчыга, кага, как, агач, ачар, кач, ар, лар, аргач, чара, ара, лач, кала, кал, чага, ала, карга, чак.

Алмагач

Ач, агач, ал, ала, алма, чал, чама, чалма, чага, чагам, чалам, алга, алгач



## Аңлатма язуы

Мәктәптә үткәрелә торган дәрестән тыш эшләр тәрбия эшен оештыруда мөһим роль уйный.Ул белем һәм тәрбия бирүдә бердәм процесс буларак, дәресләрнең дәвамы итеп бәяләнә. Әмма дәрестән аермалы буларак сыйныфтан тыш эшләрне оештыруда түбәндәге юнәлешләр күз алдында тотыла:

1) укучыларда фәнгә карата кызыксыну, белемгә омтылыш тәрбияләү;
2) фән буенча алган белемнәрне тирәнәйтү һәм дөньяга караш тәрбияләү;
3) алган белемнргә нигезләнеп укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү.

Дәрестән тыш эшләр укучыларда белем алуга һәм фәнгә карата кызыксыну уята, балаларга күп мәгълүмат бирә, фән буенча белемнәрен тирәнәйтә, сүзгә сак караш, сөйләм осталыгы тәрбияли.

Дәрестән тыш эшләр, нигездә, белем һәм тәрбия бирү максатыннан чыгып эшләнә. Ул дәреснең дәвамы буларак укучының яшь үзенчәлекләренә туры китереп үткәрелә. Дәрестән тыш эшне оештыруда, җирле региональ компонентлар киң урын ала.

Татар халкының гореф – гадәтләренә, йолаларына, халык авыз иҗатына нигезләнгән чаралар еш үткәрелә, чөнки аларда халыкның рухы, тарихы киң чагыла. ”Әлифба”, “Кәозге уңыш”, истәлекле даталарга, әдәп- әхлакка өйрәтүгә багышланган чаралар балаларда зур кызыксыну уята.

Бу методик кулланмада башлангыч сыйныфларда дәрестән тыш эшләрнең кайберләре бирелде. Һәр иҗади эшләүче укытучы аларны үзгәртә ала. Кичәгә әзерләнгәндә

сыйныфның яшь үзенчәлеге, үсеш дәрәҗәсе исәпкә алына.

## Сыйныф сәгате

**Тема:Яхшылык эшләргә ашыгыйк!**

**Максат**:Укучыларда кешелеклелек, шәфкатьлелек, миһербанлылык, олы җанлылык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләү; изге эшләр эшләргә рухландыру.

**Җиһазлау**: мәкальләр, укучылар ясаган рәсемнәр, чәчәк формасында гүзәл сыйфатлар; компьютер.

## Дәрес барышы.

Сыйныф сәгате Ф.Яруллинның ,,Яхшылык эшләргә ашыгыйк!”дигән шигырен тыңлау белән башланып китә.

Актыкка сулышны алганда
Уфтанмас өчен җан ачынып-
Кулларда егәрлек булганда,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.
Күтәрик егылган гөлләрне,
Матурлык калмасын басылып.
Холкыбыз бик сабыр булса да,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк!
Булмасын нәф(е)себез безгә баш
Без аңа үзебез баш булыйк.
Яманлык җиңелсен дисәк без,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.
Ходайның һәр бирмеш көнендә
Бер матур як белән ачылыйк:
Һәркемнең гомере бер генә,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

-Шигырьдә сүз нәрсә турында бара?
Әйе,яхшылык эшләргә кирәклеге турында.

-Укучылар, быелгы ел республикада нинди ел дип игълан



**Рәсем буенча йорт хайваннарына кушамат табарга**
Шул кушаматлар белән җөмлә төзергә




## “Яшелчә” бакчасы уены

Тактага “Яшелчә бакчасы” һәм “Җиләк- җимеш” бакчасы стенды эленә. Уенда катнашучы 2 командадагы өстәлдән бер предметнырәсеме ясалган карточканы ала һәм аны “яшелчә” ягъни җилә- җимеш бакчасы” дип язылган таблиөа- плакат беркетә. Куеп бетергәннән соң предметларның төрле билгеләре әйттерелә.

| “Яшелчә бакчасы” | “Җиләк- җимеш бакчасы” |
|---|---|
| Кыяр | Алма |
| кишер | груша |
| суган | чия |
| помидор | җиләк |
| редиска | слива |
| кабак | лимон |

### Җиләк- җимешләр, яшелчәләргә карата капма- каршы командага тамышмаклар әйтешү

Безнең мәктәп

2.Соскы борын- бакылдык,



Күп сөйләшә- такылдык.
Аңар әйтәләр үртәп:
Корсак батыр син, **үрдәк!**

**“Бәрәңге утырту һәм җыю”**

Бу уен сездән җитезлекне сорый. Сез күзләрегезне бәйләп, берегез бәрәңгене чиләккә җыя, ә икенчегез утырта һәм шулай дәвам итәргә тиешсез.Кайсы команда алдан бетерә, шул җиңә.

**Күз бәйләп өй рәсеме ясау**

Тактада өй рәсеме ясыйлар

**Ребусны чишү**

1 командага:

| |
|---|
| 100 ек |
| 6 н |
| 5 мәт |

2 командага:

| |
|---|
| әй 1 |
| 100 лек |

| |
|---|
| 100 ә |



ителгән иде әле?



**-Хәйрия елы.**

-Бу ел ни белән үзенчәлекле иде, без нинди эшләр башкарырга тиеш идек.

-Дөрес, укучылар. Быел башланып киткән ел - кешеләрнең бер-берләренә карата моңарчы күрелмәгәнчә миһербанлы, ярдәмчел һәм хәерхаһлы булулары белән дә истә калачак.

-Хәйрия нәрсә дигән сүз соң ул? (мохтаҗларга ярдәм итү)

-Нинди кешеләр ярдәм итәләр?

-Карагыз әле тирә-юнегезгә: бөтен акчалы кешеләр дә бәхетлеме?

-Киресенчә, акча бүлешә алмаучы туган-тумачалар, ата-аналар һәм балаларны бүген һәр тарафта очратырга була. Баксаң, матди муллыкны күңел байлыгы гына бәрәкәтле итә ала.

**II. Яңа белем һәм күнекмәләр булдыру.**

Безнең бүгенге тәрбия дәресебез хәйрия елы белән бәйле. Әлеге сөйләшүебез телдән журнал чыгару формасында булачак.



1. "Яхшылык эшләргә ашыгыйк" дигән телдән журналыбызның беренче битен ачабыз. Ул: "Яхшы гамәлләр турында халык" дип атала.

Әйтем һәм мәкальләрне дәвам итегез:

Кешегә яхшылык итсәң,., (үзеңә файда булыр)
Яхшылык иткән кешенең...(файдасын бел)
Яхшылык итсәң,...(яхшылык күрерсең)
Яхшылык ташны да. ...(эретә)
Яхшылык итсәң, яшер,..,....(яхшылык күрсәң - белдер).
Яхшылык ит тә, диңгезгә ташла, балык белер
(балык белмәсә, халык белер).

2. Журналыбызның икенче битен ачабыз. Бу биттә Вил Казыйхановның "Вөждан газабы" шигыре белән танышырбыз. Әгәр дә Ләлә киресенчә эшләгән булса, ул нинди эшләр башкарыр иде? Нәрсә ул вөждан?

"Вөждан газабы"

Боргалана-сыргалана
Йоклап китәлми Ләлә.
Әнисе дә сизеп алды:
"Авырыйсыңмы әллә?"
"Юк",-дигән булды да кызый,



һәм фиекрләү сәләтләрен үстерү; хезмәткә, йорт хайваннарына мәхәббәт тәрбияләү

**Җиһазлау:** урындыклар, бау, җеп, конфет, кулдан ясалган плакатлар, уенчык гөмбә

**Конкурс барышы:**

Исәнмесез укучылар! Бүген сезнең блән конкурс үткәрергә булдык. Бу конкурста без сезнең житезлекне, тапкырлыкны сынарбыз. Конкурсның исемен беренче җиңүче команда беләчәк.Хәзер ике командага бүленәбез. Өстәлдән номерлар язылган кәгазьләрне аласыз. 1 цифры язылган булса, 1 командага, 2 цифры язылган булса, 2 командага утырасыз. Һәрберебез актив катнашыйк һәм җиңәргә тырышыйк. Очколар куелып барыла.

**“Бау тартыш”**

Һәр командадан 1 укучы чыга. Ике урындыкны арт ягы белән куеп, артка карап утырасыз. Ә бауны урындыклар астына сузып куябыз. 1, 2, 3 дигәч, бауны үрелеп, үзегезгә таба тартырга, кем алданрак тарта, шул җиңүче була.

**“Командирлар ярышы”**



Табышмакның җавабын тап:

1. Кешенең якын дусты,
Йортның тугры сакчысы.
Аннан гел игелек көт

Ә исеме аның ничек? - **Эт!**

унга тәгәрәтә, үзе өенә кереп китә)

*Б*алалар поезд барган хәрәкәтләр ясап чыгып китәләр. Бер укучы урындыкта утырып кала.

**Бала.** (Уяна, исни) Әллә йоклап алдым инде, компьютерда утыра торгач. Нинди кызык төш күрдем. Урман, имеш, Убырлы, имеш. Әй, юк, ул бит телевизордан "Кучтәнәч" тапшыруын алып баручы Дәү әнигә охшаган иде. (кәрзиненә күз сала) Әбәү, бу нинди җиләк-җимешләр, чәчәкләр икән урамда кар-бураннар уйнап торганда?! Ә-ә-ә, бик яхшы, эти-әниләр, кунаклар белән бергәләп чәй эчәрбез.

## «БАТЫР» КОНКУРСЫ

**Максат:** балаларны тапкырлык, җитезлек, активлык



Бер мәлгә туктап калды.
Күзен яшерде юрганга,
Авыр итеп тын алды.
"Әйткәч әйтим, әни,-диде-
Бүген мин трамвайда
Урынымны бирмәдем, ди,
Басып торган бабайга.
Ышан әни, мондый хәлләр
Башкача кабатланмас
Хатаңны аңлагач, кызым,
Вөҗданың газапламас.

Ә хәзер Җ..Тәрҗемановның „Сиртмәле кое" шигырен тыңлап китик.

Сиртмәле кое янында
Балалар күңел ача.
Ап-ак чәчле Зөһрә әби
Су алырга маташа.
Сиртмәле кое бик тирән,
Төбе дә һич күренми.
Зөһрә әби тарта...тарта...
Чиләге һаман менми.
Бер, ике, өч...җитми бит көч,
Тагын аз гына калды.
Зөһрә әбинең бу хәлен
Мәликә күреп алды.
Чиләкле суны коедан
Мәликә алып бирде.
Әй, куанды Зөһрә әби,
Зур үс, акыллым!-диде.


-Балалар, Мәликә нинди кыз?(Җавапларны тыңлау). Мәликә-ярдәмчел, шәфкатьле бала. Шәфкатьле кеше һәрвакыт рәхимле, кайгыртучан була.

3. Журналның өченче битен ачабыз. Аның бу битенә "Без кылган изгелекләр" дигән исем бирелгән.

-Укучылар,сез тормышта нинди изге гамәлләр эшли аласыз? (Автобуста урын бирү, өлкәннәргә авыр әйберләрен күтәрешү, күрше әбигә азык-төлек, дару, су алып кайту, сукыр кешегә юл аркылы чыгарга ярдәм итү, хайваннарны карау, кошларга оя ясау, агачлар утыртып үстерү, чишмәләрне чистарту, укуда артта калучыларга ярдәм итү һ.б.) Ә хәзер укучылар үзегезнең кылган яхшылыкларыгыз турында сөйләп китегез әле.(Укучылар сөйли)




4. Журналыбызның дүртенче битенә "Яхшылыклар - рәсемнәрдә"дигән исем бирәбез. Сезгә "Кылган яхшы эшләребез" дигән темага рәсемнәр ясап киләсе иде. Әлеге биткә шушы рәсемнәрне урнаштырырбыз, (һәр укучы үзе ясаган рәсем турында аңлатып сөйли).




5.Журналыбызның соңгы битен ачабыз. Аның бу битенә



**Җыр "Туган тел"** (Г. Тукай сүзләре, халык көе)

**Әби**: Шулай булсын, балалар. Карагыз әле, балалар, киткәнче чәчемне тарасагыз икән, тырма өй артында ятадыр.

**Кыз**:И, әбекәй, тырма башыңны авырттырыр. Синең агач тарагың да бар. (Әбинең чәчен тарап үрәләр)

**Кыз**: Әбекәй, минем әбием башына калфак белән ак яулык ябынып йөри. Сиңа да бик килешер иде. Әйдә әле әби, сиңа да шулай киертик әле. (Калфак кидерә һәм ак яулык бәйләтә).Бу киемеңне дә алмаштырыйк, матур күлмәкләреңне ки. (Әби киенеп чыга).

**Кыз**. Әбекәй, кәлүшләрең дә искергән икән, минем чүәкләрем сиңа таман гына булыр. (Әби аяк киемен алмаштыра.

**Әби**: Ай рәхмәт, балалар! Карт кешене олыладыгыз, йөз елга яшәрдем, ахры, биисем килеп китте бит. (Балалар белән бергә күмәк бию башкарыла).

**Әби**: Уф, арыдым. Уңган, булган балалар икәнсез. Минем янымда гына калсагыз икән!

**Бала**: Без тагын килербез әле.

**Әби**: Ярый, эти-әниләрегез, укытучыгыз көтәдер. Юл күрсәтим үзегезгә. Менә бу вагоннарда нинди сүзләр бара? Я, әйтеп карагыз әле.

( **Вәкил, авыл, тавыш, хайван** )

**Балалар**: Вәкил, авыл, тавыш, хайван.

**Әбн.** Кайсы вагон белән кайтасыгыз килә?

**Балалар**. "Авыл" дигән вагон белән.

**Бала**. Рәхмәт сиңа, әбекәй! Безгә кунакка кил.

**Әби**: ( Әби күчтәнәчләрен бирә). Ярар, балалар. Менә серле йомгагым, сезгә юл күрсәтер. ( Ул йомгакны

**Әби**: (Кулына кабартылган шар ала)
Әпсен, төфсен,
Шайтан үтсен,
Җилләр иссен,
Төтен чыксын,
Шар серен ачсын
(Шарны шартлата, язу чыга һәм алып укый)

Телеграмма

**Тиздән без сезнең янга**
**килеп җитәрбез.**

Әдәбият, Татар теле дәресләре

( **"Әдәбият", "Татар теле** "түргә узалар.)
**Әдәбият**: Мин әдәбият буламын.
**Татар теле**: Мин татар теле буламын.
**Әдәбият**: Көн дә бергә йөрербез.
**Татар теле**: Бик күп белем бирербез.
**Өдәбият**: Мине укып сөйләрсең.

**Татар теле:** Мине язып сөйләрсең.
**Әдәбият**: Минем белән сөйләшеп.
**Татар теле**: Минем белән серләшеп.
**Әдәбият**: Бик күп юллар үтәрсең.
**Татар теле**: Хыялыңа җитәрсең.
**Әдәбият:** Хөрмәтле укучылар! Сез киләчәкнең хуҗасы. Сез инде зур үстегез. Чын кеше буласыгыз килсә, китапны яратыгыз, тырышып укыгыз, хезмәтне сөегез. Әти-әниегезне тыңлагыз, ихтирам итегез. Бәләкәйләргә ярдәмчел булыгыз. Туган илегезне, туган мәктәбегезне, туган телегезне яратыгыз!



"Яхшылык эшләргә ашыгыйк!"- дип исем бирәбез. Әйдәгез, бергәләп киләчәккә бурычлар билгелик.

1. Кешеләргә игътибарлы, шәфкатьле, миһербанлы булырга.
2. Табигатькә, хайваннарга карата мәрхәмәтле булырга.
3. Һәр көн игелекле гамәлләр кылырга, изге эшләр башкарырга.
4. Яхшылык барысын да җиңәчәк.
5. Кылган эшләрең белән мактанып йөрмәскә.

**///. Йомгаклау.**

Яхшылыкны кеше алдында мактану өчен эшләмиләр. Татар халкында: "Яхшылык ит тә, диңгезгә ташла, балык белер, балык белмәсә, халык белер",- дигән әйтем бар. Сез дә бу сүзләрне исегездә калдырыгыз, һәр көн игелекле гамәлләр кылырга, изге эшләр башкарырга, кешеләргә миһербанлы, шәфкатьле булырга тырышыгыз.

һич яхшылык эшли алмасаң син




Кешеләргә бик-бик теләп тә,-
Яхшы теләк телә,
Ул да кайчак,
Зур көч өстәп куя йөрәккә, - дип яза Ф.Яруллин. Әлеге сүзләр тормышыгызның девизы булсын дигән теләктә телдән журналыбызны шуның белән тәмамлыйбыз.

**Тәрбия сәгате „Бәхетле булыгыз!"**-дигән җыр белән тәмамлана.

Дөньяга килгәнсез икән,
Мәрхәмәтле булыгыз.
Кулыгыздан килгән кадәр
Игелек кылыгыз.
Һәммәгез дә безнең
Теләктән уңыгыз.
Бәхетле булыгыз,
Шәфкатьле булыгыз!
Табигатьне саклагыз сез,
Ул-изге йортыбыз.
Агачларны сындырмагыз,
Гөлләр утыртыгыз.
Онытмагыз әнкәйләрне,
Кечегез, олыгыз.
Ялгыз әби, бабайларга
Ярдәмчел булыгыз.
Җәнлекләргә мәрхәмәтле,
Рәхимле булыгыз.
Явызлыкка юл куймыйча,
Яхшылык кылыгыз.

## Ягез әле, этиләр!

Ватанны саклаучылар көненә багышланган кичә

***МАКСАТ:*** Илебезнең иминлеген саклаучы халкыбызның батыр улларына карата тирән ихтирам хисе, Туган илебезгә мәхәббәт тәрбияләү. Ватанның җырга тиң матурлыгын тоя белергә өйрәтү һәм аның тугърылыклы улы булу теләге уяту.

Дуслык, туганлык хисләре тәрбияләү.

**Зал бәйрәмчә бизәлгән.** Тактага зур корабль рәсеме эленгән. **Бәйрәм белән!** - дип язылган. Балаларның



**Әби:** Сез, балалар, бик күп беләсез икән. Үзегез әйткәләшмисез дә, тарткалаш-мыйсыз да, ахры . Бер-берегезне хурлагыз булмаса, күңелем күтәрелер.

**Бала:** Әбекәй, күңелеңне үзебезнең такмакларны җырлап күтәрик, булмаса.

**Такмаклар** (Сафина М.М. сүзләре)

Укытучы апа белән
Әниләр бик булышып,
Җиңеп чыктык әлифбаны
Өч чиректә тырышып,
Әйе шул, шулай шул,
Өч чиректә тырышып.

Төркемнәрдә уйланырга
Укытучыбыз куша.
Җавапны таба алмасак,
Ул үзе дә булыша .
Әйе шул, шулай шул,
Ул үзе дә булыша.
Алтын куллары ял тапмас
"Башлангыч" йолдызлары..
Кая барса да югалмас,
Безнең класс кызлары.
Әйе шул, шулай шул,
Безнең класс кызлары.
Без хәзергә һәммәбез дә :'
Киләчәк җимешләре.
Безнең кулга кучәр тиздән
**Әдәбият** дәресләре.
Әйе шул**,** шулай шул,
Туган тел дәресләре.

башлана.

**Белмәмеш “ Гөл, көл, сер, галим**” сүзләрен күрсәтә.

**Бала**: Көл сүзе артык, ул сүз "к" хәрефеннән башланган.

**Белмәмеш:** Рәхмәт, балалар, ярдәм иттегез.

**Буратино:** Миңа да шаян мәсьәлә бирделәр. Белмәмешкә әйттем, ул да ярдәм итмәде. Сез, балалар, ярдәм итегез әле.

**Бала:** Я, я, әйт тизрәк.

Шаян мәсьәләләр.

1. Өстәлдә 4 стакан җиләк тора иде. Фәрит 1 стаканнан җиләк ашады. Өстәлдә ничә стакан калган?

**Бала:** 4 стакан калган. Анда бит ничә стакан җиләк калган димәгән.

**2.** Өч кеше 3 сәгать поезд көткән, һәр кеше ничә сәгать поезд көткән?

**Бала:** 3 сәгать

**3.** Кошларны куркытмыйча гына ничек итеп ботакны сындырырга мөмкин?

**Бал а:** Мөмкин түгел, кош очып китәчәк.

**4.** Без кайчан 4 санын күрәбез, ләкин 16 дип әйтәбез?

**Бала:** Сәгатькә карганда.

**5.** Чыршы орлыгыннан ничә гөмбә үстерергә була?

**Бала:** Берне дә үстереп булмый.

**6.** Дәрес ахырында без нәрсә ишетәбез?

**Бала:** Кыңгырау.

**7**. Ярның бер ягында-чебиләр , ә икенче ягында-үрдәкләр. Уртада- утрау. Утрауга нәрсәләр тизрәк йөзеп килер?

**Бала:** Үрдәкләр.

**8.** Әнинең Йомшак исемле песие, Сарбай дигән эте һәм кызы Дилә бар. Әнинең ничә баласы бар?

**9. Бала:** 1 кызы



бәйрәмгә багышлап ясаган рәсемнәреннән күргәзмә оештырыла.

**Бәйрәм барышы**

Хәерле көн хөрмәтле әтиләр, кадерле балалар! Бүген без сезнең белән Ватанны саклаучылар көненә багышланган кичәгә җыелдык. Кадерле әтиләребез һәм аларга алмашка үсүче малайларыбыз! Без сезнең барыгызны да шушы бәйрәмегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Сезгә алдагы тормышыгызда зур уңышлар, корычтай нык сәламәтлек, озын гомер телибез. Ә хәзер кичәбезне башлап җибәрергә рөхсәт итегез.

Сүз укучыларга бирелә.(монтаж)

Исәнмесез, саумысез,
һәрберегез, барчагыз.
Бездән сезгә кайнар сәлам
Кабул итеп алыгыз.

Рөхсәт итегез дуслар
Пәрдәбезне ачарга.
Безнең көч белән әзерләнгән
Кичәбезне башларга.

Нигә бүген сыйныфта
Бик күңелле, бик ямьле
Чөнки бүген кунакка
Безнең әтиләр килде.

Бигрәк күңелле икән
Дуслар җыелган җирдә.
Бәйрәм итәбез бүген,
Әтиләр белән бергә.

Әти янымда булганда
Бернәрсәдән курыкмыйм мин.
Аның сүзе миңа закон,
Әтиемне тыңлыйм мин.

Әтиләрне,бабайларны
Кадерлибез, зурлыйбыз.
Чын күңелдән һәммәгезне
Бәйрәм белән котлыйбыз!

«Солдатта булган диләр» - жыр.

Билен кысып буган, диләр,
Бигрәк уңган, диләр.
Әллә каян күренеп тора –
Солдатта булган ,диләр.

Кечеләрне кече итәр,
Олыны зурлар, диләр.
Әллә каян күренеп тора –
Солдатта булган , диләр.

Комбинезон алган, диләр,
Шинелен салган, диләр.
Шинелен салса да, солдат
Гадәте калган, диләр.

**Укучылар шигырь сөйләүләрен дәвам итәләр**



Койрыктагып йөрүче.
Без нинди хәрефләр икән,
Бармы берәр белүче? (ц, *җ,*, щ, ң).
Томау төшкән кешеләр
Хәлебезне аңлыйлар.
Чөнки дөрес итеп
Алар әйтә алмыйлар (м, н, ң).

**Жыр "Әлифба".**

Разил Вәлиев сүзләре, Марат Мухин көе.

**Әби** (йокыдан уяна-уяна) Мин төшемдә жырлар ишетәмме дип торам, сез күңел ачасыз икән әле**.** Менә мин Ватан сүзен ишеттем. Аның эчендә нинди сүзләр яшеренде микән?
**Балалар**: Ата, ана, ант.
**Әби:** Ватан нәрсәдән башлана икән балалар?
**Балалар:** Ватан әти-әнидән башлана.
(Ашыгып **Белмәмеш** белән **Буратино** керә.)
**Белмәмеш**: Кара әле, әбекәй. Миңа да мәктәптә бирем биргәннәр иде. Әллә нишләп чишә алмыйм. Бу балалар ярдәм итмәс микән?
**Әби**: Әйт биремеңне, әйт. Алар бик күп беләләр, әйтерләр.
**Белмәмеш:** Укытучы апа сүзләр яздырган иде. Бу сүзләрдә нинди хата жибәрдем микән, әйтегез әле. (Болон,төтөн дип язылган язуны күрсәтә).
**Бала:** О. о хәрефләре сүзнең беренче ижегендә генә языла.

**Белмәмеш**: Бу язмада ниидИ сүз артык? (ай, әти, аю, ат, ау сүзләрен күрсәтә).
**Бала:** Әти сүзе артык, чөнки ул сүз "ә" хәрефе белән

Рәхмәт, укытучы апа!

**Жыр. "Яратам"**(З. Вәлиева сүзләре, Э.Зиннәтуллина музыкасы.)

**Әби** укучыларга "**Табышмаклы туган тел**" шигыренең жавапларын әйттерә.

Бөтен халыкта да бар ул
Ансыз уку-язу юк.
Тәртибен бутый күрмәгез
Ансы мөһим шулай ук. (алфавит)
«Әни" дип телем ачылган,
Әни сөйгән, назлаган.
Кайсыбыз соң дәфтәренә
"Ә" хәрефен язмаган?
Безнең хокукларыбызны .
Шул кадәрле кысканнар:
Беренче иҗектә генә
Язылырга кушканнар. (о,ө хәрефләре).
Берне бергә кушкач ничә?
Беләм инде, диярсез.
Сүзгә сүзне кушкач?...Менә
Анысы нәрсә дигән сүз? (кушма сүз).
Җөмләдән соң, йә уртада,
Әгәр безне куйсалар,
Бераз туктап торырга һәм
Тын алырга кушалар. (тыныш билгеләре).
Алфавитта алты хәреф:
Иң дуслар һәм туганнар.
Татар сүзләрендә генә
Кулланыла торганнар (ә, ө, ү, ж, ң, һ)
Без бары тик дүртәү генә



Данлы безнең Армиябез
Онытылмас юллар үтте.
Илебезне саклап калып
Халыкны азат итте.

Минем әткәй көн дә эшкә китә
Арып кайта аннан кичләрен.
Елмаюы итеп алып кайта
Шәфәкъләрнең алсу төсләрен.

Жан жылысын тоя күңелебез
Әткәй көчен тоя кулыбыз,
Үпкәләмәсеннәр!
Әткәйләргә гел изгелек кенә кылыгыз

Кая барма, шунда әткәй йөзе,
Кая барсам, әткәй күңелдә.
Әти генә шулай синең өчен
Жанын биреп йөри гомергә.
Рәхмәт яусын безнең әткәйләргә
Аларгадыр бөтен авырлык
Әткәйләргә якты йолдызлардан,
Я коящтан һәйкәл салырлык.

Жыр “Капитан минем абый”

| | |
|---|---|
| **Кавалерист**<br>Жиңү таңын якынайтты<br>Ул сугышта атлар да.<br>Ат уйнатып барды яуда<br>Кавалерия алдан.<br>**Очучы**<br>Мин - очучы. Без ут төяп,<br>Очтык корыч кошларда.<br>Без жиңүне якынайтып,<br>Үлем койдык дошманга.<br>**Тупчы**<br>Без – тупчылар.<br>Без дошманга<br>Аттык авыр туплардан.<br>Дошманнар торды калтырап<br>Без биргән залплардан.<br><br>**Шәфкать туташы**<br>Без, шәфкать туташлары да,<br>Озын,авыр юл үтеп,<br>Солдат гомерләрен саклап,<br>Берлинга барып життек. | **Разведчик**<br>Разведчиклар - без дошманның<br>Тылына кердек үтеп.<br>Тордык корган планнарын<br>Штабка хәбәр итеп.<br>**Партизан**<br>Мин - партизан. Без дошманга<br>Һич тынгылык бирмәдек:<br>Үз тылында поездларын<br>Яр астына жибәрдек.<br>**Командир**<br>Әнә шулай бердәм булып,<br>Дошманны аттык, кырдык.<br>Үз өненә кадәр куып,<br>Жиңү таңын аттырдык!<br><br>**Танкист**<br>Без – танкистлар.<br>Пехотага<br>Юл ачып бардык алдан.<br>Качты дошман куркып безнең<br>Корыч машиналардан. |



“5”легә генә укыдым .

**Жыр: "Өйрәтәләр мәктәпләрдә".**

**Рәхмәт** ( К. Гилмуллин шигыре. Түбән Кама шәһәре)

(Әлифба бәйрәменә)

И, мәктәбем, сентябрьдә
Кабул иттең кочагыңа.
Хәреф танып, укый-яза
Белми идек ул чагында.
Дустыбыз булды элифба,
Дәфтәрләр, каләм, партабыз.
Зур тәрәзәле классны
Хөрмәтлибез, яратабыз.
Каләм тоту читен булса,
Булышты кара тактабыз.
Барысыннан да күбрәк
Өйрәтте Мөршидә апабыз.
Шулар ярдәме белән без
Барып життек «А»дан «Я»га.
Очар коштай канатланып,
Чыктык «фән» дигән дөньяга.
Без хәзер беләбез инде,
Бүлү, кушу һәм алуны.
Безнең хәзер канатлар нык,
Һич белмәс ару-талуны.
Бу канатлар кирәк безгә
Тормыш үрләрен менәргә.
Зур үскәч, сөекле Илне
Хөрмәткә, данга күмәргә.
Барсы өчен рәхмәт, мәктәп,
Рәхмәт сиңа, кара такта!
Рәхмәт сиңа, әй, Әлифба!

Аяклары бер колач.
Борыны җиргә тигән,
Килгән ул ерак илдән. **(Ф**ил)
5. Сорыдыр төсе,
Үткендер теше.
Урманда йөри,
Бозаулар эзли.. (**Б**үре
**6.** Җәен урманда патша,
Кышын кардан да аста. (**А**ю)
Сүзләрнең беренче хәрефләреннән нинди сүз килеп чыкты?
**Балалар: Ә Л И Ф Б А**
**Әби**: Әлифба китабыгызга нәрсә әйтергә кирәк инде?
**Балалар**: Рәхмәт, Ә Л И ФБА !
**Әби**: Әлифба бәйрәмегезне безгә дә күрсәтегез инде. Мәктәбегездә нәрсәләргә өйрәткәннәрен без дә күрик.
**Әби.** (аягы белән идәнгә тибеп)
Перес, перес!! (Өйгә кереп китә). (Кулына хәрефләр тотып чыга) Менә, кара мәчем, сезнең белән сөйләшкән арада, бөтен хәрефләрне бутап бетергән. Ташлагыз шуларны чүплеккә, бернигә дә ярамас бу хәрефләр.
**1 бала.** Әбекәй, тукта әле. Без хәрефләрне тезеп бирербез, 1 нче сыйныфка укырга керүче укучыларга кирәге чыгар.
**Әби**. Алайса иң тиз җыючыга гөмбә, җиләк, чикләвек бирермен.
(Балалар хәрефләрне магнит тактасына тезәләр, әбигә бирәләр**)**
**Әби.** Менә, кулыгыздан уңыгыз . Яшь чагымда мин дә алфавитны яттан бик яхшы сөйли идем. Әлифбаны гел



Жыр: Бәхетле булыгыз!

Ә хәзер, кадерле әтиләребез, без сезне бәйгегә чакырабыз.

Хуш килдегез, үтегез
Түргә рәхим итегез
Әтиләр бәйгесендә
Көч сынашып китегез.
Бу бәйгедә тәүге тапкыр
Чыгып безнең каршыга.
Уңганмы сез, зирәкме сез-
Сыналырсыз җыр-моңда.
Яратырбыз, алкышларбыз,
Хәер- фатиха бездән.
Тапкырларның бу бәйгесе
Җиңү көтә бит сездән.

Хәзер безгә ике командага бүленергә һәм капитаннар сайларга кирәк.

1нче бәйге

Адымнар

(Бераз ара калдырып 3 сызык сызыла.)
Солдат күбесенчә ачлы-туклы. Бәйрәм уңаеннан сезне туйганчы ашаттылар.
- Менә сез өстәл яныннан кузгалып киттегез (1нче сызыкка хәтле бара)
- Сезнең эчегез авырта башлады.(2нче сызыкка)
-Артыгыздан куа башладылар.(3нче сызыкка)

2нче бәйге

«Иң яхшы бәрәңге әрчүчегә» конкурс, вымпел ясау.
Вымпел - кечерәк кенә, өчпочмаклы формадагы, символик рәсем төшерелгән флаг. Хәзер һәр

командадан бирәр кеше «Иң яхшы бәрәңге әрчүчегә»-дигән вымпел ясарлар. Ә шул арада ике кеше бәрәңге әрчер. Кем тизрәк һәм юкарак әрчи? Шул вымпелларның яхшысын җиңүчегә бирәбез.

3 нче бәйге

Рәссамнар ярышы.

һәрбер этигә ак кәгазь битләре бирелә. Шушы кәгазьгә солдат тормышыннан бер рәсем ясарга тиешсез.Ә без аларны сәхнәгә куярбыз һәм безнең сәхнәбез тагын да матурланыр.

4нче бәйге

Бию ярышы

Биючеләр биегәндә,
Идәннәре бөгелә.
Ярышларда җиңеп чыга,
Бию белгәне генә.

Башта «Катюша» көенә, «Моряк», аннары татар халык биюен бииләр.

5нче бәйге

Җыр ярышы

Җырлыйк әле, җырлыйк әле
Җырлыйк әле алтыны.
Җырласаң да килешәдер -
Бүген бит бәйрәм көне.

Шушы бәйрәмгә кагылышлы, сугыш вакытындагы җырларны кем күбрәк җырлый? (кара-каршы җырлыйлар)

6 нчы бәйге

Капитаннар ярышы

Капитаннар бәйләнгән күз белән икенче тәртиптә



**Бала**: Карагыз әле, карагыз. Әнә тегендә бер өй күренә. Янында бер әби дә утыра. Әйдәгез шунда барыйк. (Әби янынарак киләләр)

**Бала**: Исәнме әби.

**Әби:** Кемнәр сез? Кайдан килдегез? Бу урманда нишләп йөрисез?

**Бала**: Без Кәркәвеч урта мәктәбенең 1 сыйныф укучылары. Әлифба бәйрәменә хәзерләнәбез. Компьютердан Интернетка кереп карарбыз дип уйлаган идек, ялгыш урманга эләккәнбез. Менә хәзер адаштык. Әлифба бәйрәменә житешәсе бар. Безгә юлны күрсәт әле,әбекәй.

**Әби**: **Әлифба** бәйрәме дисезме балалар? Менә бу "Серле янчыгымда" урман дусларымның рәсемнәре салынган. Сез шуларны алып исемнәрен әйтсәгез, алар сезнең бәйрәмгә барырлар. Сезгә кирәк булмаса, мин аларны ташлыйм.

**Бала**: Юк, юк әбекәй, ташлама. Без аларның исемнәрен беләбез инде. Хәзер әйтәбез.

**Әби**: Ярар, балалар, янчыктан чыгарыгыз әле аларны. (Укучылар чиратлашып рәсемнәрне алалар, исемнәрен әйтәләр, тактага беркетеп куялар) Кыргый хайваннарның исемнәрен беләсез икән, ә менә табышмагымның җавабын табарсызмы?

**Балалар**: Табарбыз,табарбыз.

**Әби**: Тыңлагыз,башлыйм.

1. Башы тарак, койрыгы урак. (**Ә**тәч)
2. Төлкенең уртасында нәрсә бар? (**Л** хәрефе)
3. Киттем дип китә, кире килә. (**И**шек)
4. .Әрекмәндәй зур колач,

- Әниләргә багышлап шигырьләр сөйләдек,җырлар җырладык.
- Кичә буенча нинди нәтиҗә ясыйбыз?

Нәтиҗә:

Туып үскән җирендә файдалы кеше бул. Туган авылыңны, әти-әниеңне, укытучыларыңны ярат, хөрмәт ит!

## Әлифба бәйрәме

Максат: укучыларда укуга, хезмәткә җаваплы караш булдыру; иҗади фикер йөртү һәм сөйләм сәләтен үстерү; намуслылык, гаделлек, күзәтүчәнлек, өлкәннәргә хөрмәт, үзара дуслык сыйфатлары тәрбияләү.

Җиһазлау: компьютер, плакатлар, рәсемле әлифба, магнитлы хәрефләр, әкияти урман аланы, биремнәр язылган карточкалар.

Бер бала_компьютер янында уйнап утыра. Әзрәк уйнагач, йокыга китә һәм төш күрә.

Убырлы карчык өе, өй янында әби йон йомгагын чорный . Балалар шул аланга килеп чыгалар.

**Бала:** Урман аланына килдек
Матур урыннар күренде.

**Бала**: Тун кигән каен - унда,
Ямь –яшел чыршы – сулда

**Бала**: Әнә куян сикерә,
Аю бабай ял итә.

**Бала**: Кошлар матур сайрыйлар.
**Бала**: Урманда рәхәт булса да Өйгә кайтыйк, дуслар!



урнашкан команда әгъзаларының исемнәрен атарга тиеш.

7 нче бәйге

Боцманнар ярышы

Кайсы команданың боцманы тизрәк үз командасын буйлары буенча тезеп бетерә?

8 нче бәйге

Мотористлар ярышы

Мотористлар конструктордан фигуралар җыялар. Ә бу арада командалар балык исемнәрен белүләре буенча ярышалар.

9 нчы бәйге

Юнгалар ярышы

Бәйләнгән күз белән идәнгә чәчелгән кубикларны чиләкләргә җыялар. Кем тизрәк һәм күбрәк кубик җыя, шул җиңә.

10 нчы бәйге

Тапкырлар-зирәкләр ярышы

Кем тапкыр, кем зирәк Безнең шаян сорауларга
Җавап тапсын тизрәк.

1нче командага

1. Адәм башына нәрсә куна? (чал)
2. Нәрсә өстән аска таба үсә? (боз)
3. Рамиль 6 яше тулгач нишли?(7 нчегә китә)
4. Кемнең сакалын да кырдырырлык акчасы юк?(кәҗәнең)
5. Алтын ачкычлы малай .(Буратино)
6. Этнең кыргый туганы.(бүре)
7. Суыра торган таяк.(каләм)
8. Рәсем ясау өчен агач дәфтәр.(парта)

2нче командага

1. Нинди савыттан эчеп булмый?(буш)

2. Кайсы елда кешеләр күбрәк ашый?(кәбисә)
3. Кара мәче нинди ишектән керә?(ачык)
4. Кайсы ай календарьда юк?(һавадагы)
5. Бабай 70 яше тулгач нишли?(71 гә китә)
6. Дуңгызның кыргый туганы?(кабан)
7. Мөселманнарның иң изге китабы.(Коръән)
8. Безнең белән чиктәш республика.(Удмуртия)

Хушлашырга вакыт житте,
Тәмамланды кичәбез.
Мондый ярышлар еш булыр
Сез бик теләп килсәгез.
Бүгенгенең гүзәл бер мизгеле
Күңелләрдә калсын уелып.
Соңгы кабат булмас, язган булса,
Гөрләшербез кабат җыелып.
Ә хәзергә хушыгыз.



Гөлләр дә елмаеп баш ия:
Яшәгез, кадерле әниләр!
Сез булган урында
Сез булган урында
Мәңгелек язларның яме бар!

Жыр: "Һәрвакыт булсын кояш". ( Укучылар әниләренә үзләре ясаган открытка бүләк итәләр.)

9. Хәзер сүзне әниләрегезгә бирәбез. Алар сезне мәктәпкә кадәрге чорда ничек тәрбияләделәр икән?

1). "Бала йоклату" күренешен күрсәтергә һәм "Бишек жыры" башкарырга.

2). Сезнең балагызга 3 яшь тулды. Шул вакытын искә төшереп, балагыз белән бер уен уйнап күрсәтегез әле.

Равилова Айсылу башкаруында татар халык биюе башкарыла.

3). Иртә белән балагызны балалар бакчасына озату күренешен күрсәтергә.

4). Балагыз дәрес хәзерләгәндә кайсыгыз ( әтисеме, énисеме) ярдәм итә? Сезнең балагыз кайсы фәнне яратып укый? Кичә математикадан кайсы күнегүне эшләргә ярдәм иттегез?

5). Укучылар мәктәп тормышыннан инсценировка күрсәтәләр. Магнитофон язмасында Вәсилә Фаттахова башкаруында " Туган як" жыры тыңлана.

10. Рефлексия.

- Бу кичәдә нәрсәләр турында сөйләштек, нәрсәләр белдек?
- Туган ил, туган авыл, әниләр турында сөйләштек.
- Авылга нигез салучы Гаделшә нәселе шәҗәрәсе белән
  таныштык.

Йөрәгемнең иң-иң түрендә.
Күңел җылың, якты йөзең белән
Маягым бул гомер-гомергә.
Син барында әнкәй дөнья тыныч,
Кояш сибә изге нурларын.
Әти белән инне иңгә куеп,
Үтегез сез гомер юлларын.
Дөньяда иң газиз кеше -
Әниләр һәркем белә.
Аларның җылы сүзләре
Җанга рәхәтлек бирә.
Яратам мин әниемне
Ул да мине ярата.
Матур карашлары белән
Безне үзенә тарта.
Минем әни бу дөньяның
Иң чибәре, сылуы.
Нинди бәхет -һәр баланың
Үз әнисе булуы!
Минем әни, һич бәхәссез,
Иң сөйкемле әни ул!
Әйткән сүзе,
Кылган эше -
һәммәбезгә туры юл.
Борчыйсым килми әнине
Елмаеп, Көлеп йөрсен.
Иң матур әни икәнен
Бөтен дусларым күрсен.
Әниләр бәйрәме көнендә
Җырламый калырга буламы?
Әниләр булмаса,
Җылытыр иде кем дөньяны?



## Сөмбелә бәйрәме

Үз муллыгы белән күзләр килә ,
Йомгак ясап җәйге хезмәткә.


Максат: укучыларда зәвык тәрбияләү;танып-белү ихтияҗын арттыру, икмәккә, игенче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү;туган як табигатен сөяргә, кадерләргә, кешеләрен олыларга, ихтирам итәргә өйрәтү.

Материал: “Тәрбия”газетасы № 1, 2000 ел “Көмеш кыңгырау”газетасы № 9, 2002 ел.

Җиһазлау: Компьютер, магнитофон, мәкальләр язылган плакатлар, рәсемнәр, аппликацияләр, чәчәкләр, яшелчәләрдән фантазия өстәле.

## Бәйрәм барышы.

Хәерле көн хөрмәтле укытучылар, укучылар, кунаклар!Без бүген сезнең белән бәйрәмгә җыелдык.Сез аның темасын менә бу кроссвордны чишсәгез белә алырсыз.(Кроссворд чишү) .



1. Кыягы да тамыры да

Безне елатып сыйлый
Аның янында беркайчан
Грипп микробы булмый.(Суган)

2. Яшел чәч, кызыл күлмәк,
Винегрет булмас ансыз
Салат,икра,борщлар-
Ул булмаган аш-су сансыз ( Чөгендер)

3. Кызыл төймәсен аскан
Каршыма килеп баскан.(Миләш)

4. Түтәлдә сары бозау
Бәйләгәннәр озын бау
Ята һавага карап-
Нәрсә булыр бу?(Кабак)

5. Кызыл кызы җир эчендә
Чәчләре җир өстендә.(Кишер)

6. Балдан татлы,
Ал яңаклы,
Үсә бакчада-
Алдым акчага.(Алма)

7. Сап-сары-кояш түгел
Эчләре бүлем-бүлем.
Кабыгын әрчеп алдык
Өләштек телем-телем.(Әфлисун)

-Әйе,Сөмбелә.



Әниләр бәйрәме.
Китерегез аларга
Ак гөлләр бәйрәме!
Бирегез аларга
Җан - күңел җылысын.
Әйтегез, әйтегез
Рәхмәтнең олысын.
Кояш кебек нурын сибеп,
Кайгыларны таратып,
Әниләр яши дөньяда
Балаларын яратып.
Әниләрнең назы беләң
Без керәбез һәр көнгә.
Кояш кирәк җир йөзенә,
Әни кирәк һәркемгә.
Минем әни бик тә уңган
Өйләрне җыеп куйган.
Идәннәрне себергән,
Аш пешереп өлгергән!
Әнинең уңганлыгына
Соклана бөтен урам.
Кызы ничектер инде
Шул хакта уйлап торам.
Мин әниемне яратам,
Аңа һәрчак булышам.
Аның һәрбер кушкан эшен
Башкарырга тырышам.
Әни һәркөн иртән мине
Мәктәпкә илтә бара.
- Тырышып укы, балам диеп! - диеп,
Изге теләктә кала.
Әни, әнкәй син бит минем берәү

5. Видеомагнитофоннан Фән Вәлиәхмәтов башкаруында "Сагышларым туган якта" дигән җыр тыңлана.

- Әйе,үзенең ямьле, иркен һәм гүзәл туган ягын сагынмаучы кеше дөньяда бармы икән? Мөгаен, юктыр. Күңелләргә гаҗәеп якын, мәхәббәтле ул. Туган авыл, туган җир, туган йорт һәркем өчен дә изге һәм кадерле.

  Һәр кеше үзенең туган авылын аерым хис белән ярата, аны үзенчә матур сүзләр белән мактый. Кайда гына булмасын, нәрсә генә эшләмәсен, кеше барыбер үзенең туган ягын сагына. Кайсы шәһәрдә, чит җирләрдә генә булма, барыбер уйлар туган якта йөри. Туган авылдагы хәлләр, кешеләр, дуслар һәм туганнар турында уйлыйсың. Туган якның һәрбер мизгелен сагынасың. Төшләргә безгә бәхетле балачак бүләк иткән әти-әни, туган җирләребез кереп йөдәтә. Кеше барыбер туган ягына соң булса да әйләнеп кайта. Анда аны, аңа тормыш биргән, якты дөньяга тудырган газиз әнкәсе, газиз туган йорты көтә.

6. " Тәрбия" газетасында чыккан материал белән таныштыру.

7. Укучылар башкаруында "Кояшлы ил" җыры башкарыла.

8. Тиздән нинди зур бәйрәм булачак?

- Әниләр көне.
- Сезгә матур балачак бүләк иткән әниләрегез турында сөйләү өчен сүз сезгә - укучыларга бирелә.

( Укучылар шигырьләрен үзләре ясаган әниләренең рәсеменә карап сөйлиләр.)

Бүген олы бәйрәм -



-Ә сез Сөмбелә сүзенең нәрсә аңлатканын беләсезме?

Укытучы чыгышы:

Сөмбелә бик борынгы заманнардан ук яшәп килә.Бу бәйрәм көзге уңышлар җыеп алынгач , барлык эшләр беткәч билгеләп үтелә.

Сөмбелә аеның соңгы көне тәүлек эчендә көн белән төннең көзге тигезләшкән чорына туры килгән һәм бу көнне,15 нче сентябрьдә Сөмбелә бәйрәме үткәрелгән. Бу бәйрәм Нәүрүз бәйрәменең капма-каршы парын тәшкил иткән.Нәүрүз бәйрәме игенчелек циклын башлап җибәрсә, Сөмбелә бәйрәме аны тәмамлап-йомгаклап куйган.

Чөнки бу вакытта инде урып-җыю эшләре һәм уҗымга сөрү тәгәлләнә торган булган, ашлык әвеннәргә, кибән-эскертләргә куелган, сугылганы келәт-амбарларга тутырылган.

Укучылар чыгышы.

(Монтаж)

**Җыр: "Беренче сентябрь"**

1укучы: Күңелләргә якты нур өләшеп,
Шатлык өстәп һәрбер йөрәккә.
Үз муллыгы белән көзләр килә,
Йомгак ясап җәйге хезмәткә.
2 укучы: Табындагы икмәк, сый- нигъмәтне
Күреп ил картлары шатлана.
Муллык белән җиргә көзләр килә,
Көзге муллык кыла тантана.
3 укучы: Көз көннәре бик күңелле,
Бик күп җимешләр пешә.
Помидор, карбыз өлгерә,

Алмалар өзелеп төшә.
4 укучы: Арыш, бодайлар белән
Колхоз амбары тула.
Яхшы эшләгәч, уңыш күп
Бар кеше дә бай була.

**Жыр: „Чайкала иген кырлары”.**

Бер кулына бер ак чәчәк, ә икенчесенә алма һәм яшелчәләр салынган кәрзин тотып “Көз кызы”керә.

**Көз кызы:**

Мин “Көз кызы”, киләм сезгә,
Көзге байлык кулымда.
Муллык белән байлык телим
Кем очраса юлымда
Амбар тулы арыш , бодайларым,
Тау-тау булып өелгән,
Алмалы авыр ботаклар
. Жиргә чаклы иелгән.

Дуслар бәйрәмгә килгәнсез
Гөлдәй матур киенгәнсез.
Ниләр китердегез көзгә,
Сөйләп бирегезче безгә.

Укучылар шигырь сөйләүләрен дәвам итәләр.



- Нәрсә соң ул Туган ил?

(Әти, әни, туган йортым, ишегалдым, урамым, җиләк җыя торган урманым, балык тота торган елгаларым, мәктәбем, дусларым, укытучыларым.)

- Безнең Туган илебез ничек дип атала?
- Т А Т А Р С Т А Н .
- Бүгенге кичәнең исемен табу өчен тактага язылган сүзләрне эзлекле итеп урнаштырырга кирәк.

Авылым каршымда Туган минем шунда омтыла һаман Күңелем

Укучылар теманы әйткәннән соң, тактага тема, максат язылган плакат эленә.

- Без, бүген әниләр, туган авылыбыз турында сөйләшербез.

2. Г. Тукайның " Туган авыл" шигырен көйләү.

Тау астына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар якын безнең авылга ул.
Авылыбызның ямен,суы тәмен беләм
Шуңа күрә сөям жаным тәнем белән.

3. Бер әни авыл тарихы белән таныштыра.
4. Икенче әни Кәркәвеч авылына нигез салучыларның берсе булган Гаделшә нәселе шәҗәрәсе турында аңлата. Шәҗәрә - нәсел агачы. "Жиде бабасын белгән кеше бәхетле була"- диләр.
( Укучыларның төзегән шәҗәрәләре күрсәтелә.)

- Ә ни өчен туган авыл һәркем өчен якын?

( Төркемнәрдә уйлыйлар.)

- Укучылар, әйтик, мәсәлән каникул вакытларында, бәйрәмнәрдә туганнарыгызга, дусларыгызга кунакка берәр шәһәргә яки авылга барганыгыз булгандыр. Әйтегез әле, ни өчен бераз торгач өйгә кайтасы килә башлый? (Укучыларның фикерләре тыңлана.)

## Ачык класс сәгате.

**Тема:** Туган авылым минем каршымда,
Күңелем һаман омтыла шунда.

**Максат:** Туган авыл белән горурлану хисе,Туган илгә, әниләргә мәхәббәт тәрбияләү; үзара дус, тату, бердәм булырга өйрәтү.

**Җиһазлау:** Татарстан картасы, 'Туган авыл күренеше",Кәркәвеч авылына нигез салучы Гаделшә нәселе шәҗәрәсе, балаларның ясаган рәсемнәре, шәҗәрәләре, плакатлар, шарлар, видеомагнитофон.

### Дәрес барышы.

Хәерле көн хөрмәтле кунаклар, әниләр. Хәерле көн, балалар.

Бүгенге кичәбезне башлыйбыз.

Р. Миңнуллинның "Җирдә миңа ни кирәк?" шигырен уку.

Җирдә миңа ни кирәк?
Әти дә әни кирәк.
Җирдә миңа ни кирәк?
Без яшәрдәй өй кирәк.
Җирдә миңа ни кирәк?
Әллүкиле көй кирәк.
Җирдә миңа ни кирәк?
Тукай туган тел кирәк.
Җирдә миңа ни кирәк?
Туган үскән ил кирәк.
Җирдә миңа ни кирәк?
Мәңге имин ил кирәк.

-Бу шигырьдә сүз нәрсә турында барды?
(әти,әни,өй, көй, туган тел, ил сүзләрен әйтә баралар һәм агачка беркетелгән яфракларны ачалар.)

- Бу сүзләрне икенче төрле ничек атап була?

( Яфраклар икенче ягы белән әйләндерелә һәм " Туган ил" дигән язма килеп чыга.)



Алма:
Бакчабызда үсә алма,
Ул кызыл була, ал да.
Тәмле, шикәр бал гына.
Аны гел алмаска түгел,
Рөхсәте булса ал гына.

Чия:
Чияләр тора тулып,
Тамып төшәрдәй булып,
Ә пешеп җитмәгән чия-
Файдасыз-тешкә тия.
Өлгергән чияләр күрсәң,
Авыздан сулар килә.

Миләш:
Көз житкәнен миләш уйламый да,
Ул кызарып тулган күр, әле,
Юк, саргаеп түгел, уттай янып,
Каршылый ул көзге көннәрне.

Арыш:
Кар астында кыш үткәрәм,
Яшел туныймны киеп,
Көздән чәчеп калдырганга
Өлгерәм мин иң элек.

Бодай:
Эшкәртсәләр бөртегем,
Бөтен шартын китереп,
Минем оннан күмәч пешә,
Күбек кебек күпереп.

Кабак:
Карагыз әле бер генә
Менә миңа кабакка.
Турап куйсагыз мин сыймыйм
Хәттә тугыз табакка.

Кәбестә:
Безнең мәктәп балалары
Яшелчә дә үстерә.
Мәктәп глобусыннан зур,
Мәсәлән, мин кәбестә.

Бәрәңге:
Ә бәрәңге, бәрәңге
Эрелеген күр әле.
Сап-сары бәрәңге белән
Тирән базыбыз тулды.

**Көз кызы:** Алдагы көннәрегездә,
Телимен мин уңышлар.
Муллыкта, рәхәт тормышта
Яшәгез, нәни дуслар!

**Җыр: „ Көз”.**(Көз кызын түгәрәккә алып җыр башкаралар**).**

## КВН

1.Командаларның сәламләве.
2.Көз турында бер шигырь сөйләргә.
3.Комндалар үзләре әзерләп килгән мәкальләрне әйтәләр.
4.Кайсы сүз артык?(Таблода сүзләр чыга, артык сүзне табарга).
5.Бу картиналарда кайсы ел вакыты сурәтләнгән?
6.Кискән яфракларны җый һәм нинди агачныкы икәнен әйт.
7.Гөмбәләрне таныйсыңмы?(Гөмбә исемнәре язылган карточкалар бирелә, шулар арасыннан ашарга яраклыларын гына сайлап җыярга).
8.Орлык салынган капчык күрсәтелә.Укучылар нинди орлык икәнен әйтергә тиешләр.
9.Көй уйнала(яшелчәләр капчыкта күренмиләр, көй уйнап бетерүгә яшелчәләрне капшап белергә).
10.Пазлылардан картина төзү.
Картина төзелгән арада 1, 2 нче сыйныф укучылары белән эш.(“Дәвам ит”уены һәм “Яшелчә, Җиләк-җимеш бакчалары”)
Йомгаклау: Уенга нәтиҗә ясала, җиңүче команда билгеләнә.



кешелеклелек сыйфатлары язылып бара.

Игътибарлы, тәүфыйклы , мәрхәмәтле,бәхетле, кайгыртучан, игелекле.

**Укытучы сүзе**: Әйе, шәфкатьле булу – барлык күркәм гадәтләрнең башы, әдәплелекнең нигезе.Чөнки бары тик шәфкатьле бала гына күркәм гадәтләргә ия, бәхетле, тәүфыйклы, мәрхәмәтле, игътибарлы, кешелекле була ала.

Балалар, кешеләрне матур эшләрегез белән сөендерегез. Әйе, игелекле кешене һәркем ярата, хөрмәт итә.

Экранда “ Халык әйтсә, хак әйтә” исемле рубрика астында мәкальләр языла.

Адәмне адәм иткән - әдәп.

- Әдәпле кеше солтан, әдәпсезнең бите олтан.
- Җаның олы булса, эшең дә олы.
- Ат үләр – ияре калыр, адәм үләр – даны калыр.
- Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен.
- Әдәпленең күлмәге сәдәпле, үзе күркәм гадәтле.

( Балалар мәкальләрнең мәгънәләрен аңлаталар, укытучы тулыландыра).

**Укытучы сүзе:** Үсә барган саен, үзегездә әдәплелекнең кешене сөендерә торган өр – яңа сыйфатларын булдыру өчен тырышыгыз. **“Әдәпленең күлмәге сәдәпле, үзе күркәм гадәтле”**, - дип юкка әйтмәгәннәр. Шулай булганда гына гадел, намуслы, инсафлы, рәхимле, мәрхәмәтле, тәүфыйклы һәм ниһаять, бәхетле булырсыз!

Ильшат – бертуган абыйсы Шакирзянов Ришат турында сөйләде).

Аларның фотосурәтләре экранда күрсәтелә.

**Укытучы сүзе:**

Еллар уза, дөньяга яңа буыннар килә. Әмма канкойгыч сугышлар турында онытырга беребезнең дә хакы юк. Ватан сугышы каһарманнары, Әфганстан, Чечня җирләрендә сугыш кырында һәлак булган, хәбәрсез югалган якташларыбыз алдында баш иябез!

Аларның батырлыклары безне яхшы , изге эшләргә этәрсен иде.

Халкыбызда әүвәл - әүвәлдән ятимнәргә, кулы – аягы гарипләргә, язмыш кимсеткән, табигать кыерсыткан кешеләргә карата аерым бер караш яшәп килгән.

Мондый кешеләргә шәфкатьле булганнар. Бүгенге авыр заманда шәфкатьле булу бигрәк тә кирәк. Ана назын, ата сөюен күрмәгән күпме сабый, ятим бар.

Инвалидлар, картлар йортлары күбәю дә безгә, яшь буынга, шул турыда чаң суга.

Салкын, буранлы кышкы көннәрдә , җәйге көннәрдәге кояш кебек , йөрәгебездә кечкенә генә кояш тудырыйк.

Кояшыбыз әкрен генә зурая барсын, аңа нурлар җибәрик. Яхшылык нуры, изгелек нуры, шатлык нуры. Шушы нурлар ялгыз – карт – карчыкларның, тол хатыннарның, гарипләрнең, ятим балаларның йөрәкләренә үтеп керсен иде дә, бәхет –шатлык белән күңелләрен җылытсын иде.

**(Укучылар кешелеклелек сыйфатларын саныйлар)**

Экранда кояш рәсеме. Нурларына балалар санаган




## Әлифба әкиятләр илендә
**(Тиремкәй әкиятенә ияреп)**




Укытучы. – Борын–борын заманда яшәгән ди бер тычкан. Бик акрын йөргәнгә, аңа Әкрен дип исем кушканнар. Үсеп буйга җиткәч, тычканыбыз дөнья күрергә, яңа тормыш башларга дип, урман буйлап киткән. Бара– бара ул бер өйгә килеп җиткән. Бу өй серле икән. Серен әкият азагында чишәрбез.

Ишеккә кагылуы була, анда серле бирем пәйда була.

Бирем.



Укытучы. - Безгә тычканның серле өйгә килгәндә, ял итәргә тукталган урыннарын әйтергә кирәк. Әкрен әлегә укый да, яза да, саный да белми. Ярдәм итәбезме аңа?

Балалар ярдәм итә.(Җавап : 26,28, 30,32 нче км ларда ял иткән)

- Бик дөрес, булдырдыгыз! Ишек үзеннән үзе ачылып китә, Әкрен тыныч кына шунда яшәп кала. Көннәрдән бер көнне, Л хәрефен җитәкләп, бака баласы - Лап – Лоп килеп ишек шакый. Кайсыгыз әйтә: ни өчен ул Л хәрефен ярата икән?
Җавап: Исеме Л хәрефеннән башланганга.
Тычкан өйдә хуҗа булса да, ишекне ачып, Баканы өйгә кертә алмый. Белгәнебезчә, бу - серле өй. Ишек ачылсын өчен бака да бирем үтәргә тиеш була. Лап – Лоп бик кечкенә, әле мәктәп яшенә җитмәгән. Ә менә без, укучылар, аңа ярдәм итә алабызмы?
Җавап: Әйе, бик рәхәтләнеп.



үстереп яталар. Фахрутдинов Хәмит – Ташлы – Елгадан
.

**Укытучы сүзе:** Алар барысы да гаиләле, үрнәк гаилә булулары белән безне куандыралар.

Әфган вакыйгаларыннан соң 2 дистәдән артык ел үтеп китте. 10 ел буе дәвам иткән сугыш нәтиҗәсендә һәлак булган, контузия, җәрәхәт, авырулардан үлгән, хәбәрсез югалган меңләгән сугышчы һәм хезмәткәрнең исеме хәтердән беркайчан да җуелмас.

**Укучы :**

Югалтулар алып килде сугыш,

Күпме дуслар кайтмый калдылар.

Шул дусларның йокыларын саклап,

Ак каеннар моңсу шаулыйлар.

**Укытучы сүзе :**

Сугышлар бүген дә дәвам итә. Күпме яшь – яшь егет Чечня җирендә ятып калды. меңләгән ата – аналар газиз улларын югалтты.

Солдат сугышны сайламый. Ул сугышны игълан да итми. Ул бары тик, биргән антына һәм хәрби бурычына тугрылыклы булып, халык һәм Ватан исеменнән бирелгән боерыкны гына үти. Аның каһарманлыгы, батырлыгы, Ватанга ихтирамы һәм мәхәббәте нәкъ менә шунда күренә.

( **Балалар** Чечняда хезмәт иткән абыйлары турында **сөйлиләр**:

Алмаз – абыйлары Гибазов Айдар һәм Зиннатов Ринат турында;



хөкүмәте карары

нигезендә Әфганстан территориясенә

чикләнгән күләмдә гаскәрләр кертелде.

**Сугыш ...** Ул ел буе дәвам иткән сугыш...

Күпме кешеләрнең гомерен өзгән каһәр суккан сугыш...

Безнең республика территориясеннән чакырылган 9 меңнән артык солдат һәм офицер әфган җирендәге сугыш хәрәкәтләрендә катнашты. 250 сугышчы – төрле орденнар,1415 кеше медальләр белән бүләкләнде.

Экранда районнан сугышта һәлак булганнар слайды

Безнең авылдан да Әфган җирендә интернаиональ бурычын үтәгән егетләр яши. Аллага шөкер, алар исән – сау туган җирләренә әйләнеп кайттылар.

( Балалар Әфган җирендә хезмәт иткән солдатларның исем – фамилияләрен атыйлар. Нәгыймов Мөнир – Бурсык- Елга авылыннан, 2 бала атасы; Бәдретдинов Ринат – Кәркәвеч авылыннан , 3 ул үстерәләр. Кече улы Ильшат әтисенең батырлыклары турында сөйли. Әтисе Әфган җирендә танкист булып хезмәт итә.

Гаязов Альберт – 3бала атасы- Ташлы Елгадан. Альмиев Марсель – Бурсык – Елгадан- 1 кыз, 1малай





**Менә сезгә рәсемнәр**



Укытучы. - Рәсемнәргә карап, исемнәрен иҗекләргә бүлеп язарга кирәк.
(Ат, кә-җә, сы - ер, пе - си дип яза һәм сүзләрне иҗеккә бүлә, сузыкларын билгелиләр.)
Лап – Лоп та өйгә уза.

Укытучы. - Бака белән тычкан тыныч кына гомер иткәндә, Куян, узып барышлый, Серле өйгә кермәкче була. Аның әлегә исеме юк, аңа кем дип исем кушыйк?
Җавап: Исеме - Иң –иң озын колак, шуңа күрә кулына И хәрефе тоттырыйк



**Бирем.** Мәсьәлә. Алмагачта 10 алма
Алар пешкән, алланган.
Берсен алды Әнисә
Агачта калды ничә?
Балалар җавабы: 10-1=9



итәләр дисәң, дөрес тә булмас инде, аларның дөньясы тукталган, бер урында тапталып торган кебек тоела миңа.

Без, сезнең белән андый ялгыз карт – карчыкларга үзебезнең ягымлы карашыбызны, татлы сүзебезне, кулыбыздан килгән ярдәмебезне кызганмыйк.

Сугыш вакытыннан ук “Тимурчылар” хәрәкәте үзенең изге эшләре белән карт – карчыкларны хәйран калдырган. Хәзер дә бу эш дәвам ителә.

(Дәрескә әзерләнгәндә сыйныфтагы укучыларга әдәплелек кагыйдәләренә кагылышлы инсценировкалар әзерләргә кушыла).

1) **“Урамда”** . Гүзәл мәктәптән кайтып бара, менә ул күрше әбисен күреп алды. Әбинең кулында ике сумка иде. Гүзәл тиз генә барып әби белән исәнләшә һәм аның бер сумкасын алып әбине озата.
2) **“Нәни тимурчылар”** . Миниса апа Кәркәвеч авылында хөрмәткә лаеклы карчык.

Сугыш вакытында шәфкать туташы булып эшләгән.Ләйсән белән Азат Миниса

апаларга килделәр, исәнләштеләр.Хәлен белгәч, өен җыештырдылар, су китерделәр.Миниса апа аларны тәмле чәй белән сыйлады.

Укытучы сүзе: Бу гади генә күренешләр. Барыбызның да кулыннан килә торган эш.

Бер сугыш яралары төзәлми, икенчесе башлана.

**Экранда Әфганстан сугышы күренешләре.**

1979 нчы елның 27 нче декабрендә Советлар Союзы

Әбиләр дә, бабайлар да
Бу бәйрәмнән нидер көтә:

Ялгыз карчык картын көтә-
Гәрчә инде сугыш җиле
Ачы хәбәр җиткерсә дә ...
Әле һаман төшләрендә
Кара хатлар китерсә дә,
Керә аңа якты ак төш –
Күз алдында бер күренеш –
Солдат кайта авылына,

Ул йөгерә каршысына ...

Алтмыш бер ел –
Бер үк төш ул,
Кабатлана торган көч ул!
Уяна ул өметләрдә...
Шул ук тормыш ...
Шул агыш...
Күңелдә - 61 яшьлек

Таталы сагыш, ачы сагыш.

**Укытучы сүзе:** Бу шигырьне Кәркәвеч авылында

95 яшен тутырган, хөрмәткә лаеклы Шигапова Сарабикәгә багышлап оныкчыгы Лариса язган. Сарабикә әби 2 баласын берүзе үстергән. Андый карчыклар безнең илдә бик күп булган. Алар ирләренә тугры булып калганнар, шуңа күрә аларны солдаткалар дип йөртәләр.

Сарабикә әбинең бәхете бар, ул оныгы, оныкчыклары, киленнәренең кадер – хөрмәтендә яшәп ята. Ә бит балалары, туганнары була торып та картлар йортында гомер итеп яшәп ятучы катрлпр, карчыклар да бар. Гомер



Укытучы. - Бик дөрес. Ә хәзер әйдәгез, ял итеп алыйк. Музыкаль тәнәфес



***Руслан белән Алмаз үзләренең такмакларын җырлыйлар.***

Укытучы: Балалар, әйтегез әле, бу йортта хәзер кемнәр яши башлаган?
Җавап: Әкрен , Лап- Лоп , Иң – иң озын колак тату гына яшәгәннәр, ди.
Укытучы: Беркөнне өй кырыннан Фырт кына киенгән төлке узып бара икән.




Билгеле инде Серле йорт аны да җәлеп итмичә калмый.Тик ул да укый – яза белми шул. Хәйләкәр дустыбызга ярдәм итәбезме?

Балалар. - Әйе.

**Бирем**. Төлке – хәйләкәр. Тик әкиятләрнең берсендә ул да, алданып, авызын ачып калган. Бу әкиятнең исеме ничек?

Балалар җавабы:“Төлке белән каз”

Көннәрнең берсендә Серле йортка Бүре килә.



**Укытучы**: Әйе, ярдәмгә мохтаҗ кешеләр, ятимнәр яши безнең арабызда.

Кешелек дөньясы нинди генә фаҗигаләргә юлыкмаган да, нинди генә афәтләр кичермәгән ул?

Бөек Ватан сугышы, Афганстан, Чечнядагы сугышлар.

Сугыш... Нинди авыр, каһәрле, шомлы сүз бу! Ул ничә миллион кешеләр гомерен өзгән, күпме баланы ятим иткән, аналарны тол калдырган ...

Экранда сугыш күренешләре

1418 көн һәм төн дәвам иткән шушы сугыш илебезгә күпме хәсрәт, кайгы китерде.

Әйдәгез әле, балалар, сезнең нәселдән дә сугышта катнашкан бабай, абыйлар, туганнарыгызны әйтеп китегез әле.

(**Укучылар**: Илнар: - Минем бабам сугышта булган. Ул Бөек Ватан сугышы инвалиды.

Алмаз: - Минем абыем- Гибазов Айдар Чечняда хезмәт итте.

Мөнирә: - Ә минем әтием Афганстанда интернациональ бурычын үтәгән.).

Экранда Шигапова Ларисаның “Татлы сагыш” шигыре .

Бер укучы шигырьне яттан сөйли.

**“Татлы сагыш”**

Яз җитүгә, туган илгә
Кайта казлар, канат кагып.
Бөек Җиңү көне җитә -
Бәйрәм итә барча халык.

Бер укучы сәнгатьле итеп укый.

“ Кешегә иң күп яхшылык эшләгән кеше генә яхшы кеше була.  Кешенең иң кадерле нәрсәсе – аның гомере. Гомер аңа бер генә   тапкыр бирелә, һәм аны мәгънәсез үткән еллар өчен   газапланмаслык итеп, әшәкелек һәм ваклык белән үткән    көннәр өчен хурлык утында янмаслык итеп үткәрергә кирәк.

Үлгән вакытта, бөтен гомерен, бөтен көчен дөньядагы иң изге

нәрсәгә - кешелекне азат итү өчен көрәшкә бирелде, дип әйтерлек булсын.”

**Укытучы сүзе:**

- Балалар, яхшы кеше нинди була ул?
- Сез ничек уйлыйсыз?

( Балалар җавабы:  Кешелекле, игелекле, мәрхәмәтле, игътибарлы һ. б. сыйфатларга ия булган кешеләр.)

Укытучы : Әйе, укучылар.

Экранда “ Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен”,- дигән сүзләр чыга.

Укытучы:  Укучылар, 2007 ел – Татарстанда нинди ел дип игълан ителде әле?

(Балалар җавабы: 2007 ел – Хәйрия елы.)

Экранда Хәйрия елының символы күрсәтелә.






Билгеле инде, ул да керә алмый.
Ярдәм итик бүрегә.
Итик.

**Бирем.** Сүзләрне башта уңайга, аннан кирегә укырга.

Сөт , чак, чага, таш, аю, акча, сат, так, таза.
Балалар:
Сөт –төс, чак – кач, чага – агач, таш – шат,
аю – юа, акча – ачка, сат – тас, так – кат,
таза – Азат.

Укытучы. Булдырдыгыз!  Шулай итеп,  алар бишәү яши башлыйлар.
Хуҗалыгын тикшереп йөргәндә,  урман хуҗасы  Аю йортны күреп ала, кемнәр яшәгәнен белергә тели.




Тик ишек аңа да ачылмый. Йокы ратканга күрә, дәресләрне күп калдырган икән дә күп нәрсәне белми калган.

Укытучы. - Ярдәм итикме үзебез?

Балалар. - Әйе.

**Бирем.** Менә бу хатта бирем. Кем әйтер: 2008 нче ел Татрстанда һәм Рәсәйдә нинди ел дип игълан ителде?

**2008 – Гаилә елы**



Әлифбаны дәвам итеп,
Туган телне укырбыз.
Татар телен өйрәнүне
Бурыч итеп алырбыз.

Балалар, кунаклар “Туган тел” җырын башкара. 1 нче сыйныф укучыларына истәлекле бүләкләр тапшырыла.Әти- әниләр белән берлектә уеннар үткәрелә. Бәйрәм чәй табыны янында дәвам ителә.

## Сыйныф сәгате

**Тема : Әдәпленең күлмәге сәдәпле, үзе күркәм гадәтле**

Максат:

1) кешеләрне шатландыру – үзе бәхет булуына төшендерү;
2) укучыларда инсафлылык, өлкән буын кешеләренә мәхәббәт,
   ветераннарга олы хөрмәт һәм ихтирам тәрбияләү;
3) шәфкатьле бала гына күркәм гадәтләргә ия, бәхетле, тәүфыйклы, мәрхәмәтле, кешелекле булуын аңлату.

**Материал**: “Әдәплелек дәресләре”, Л. И. Галиева, К., 1995 ел, экран, видео, DVD, рәсемнәр, фотокарточкалар.

**Дәрес барышы :**

Экранда Н. Островский сүзләре.

**“Ф” хәрефе**

Филне күргәч циркта,
Аптырап калдым берара
Туплы уйный, су сиптерә
Барысын да булдыра.

**“Б” хәрефе**

Үпкәләгән бабакаем
Бакчага чыгып баскан
Без уйнаган арада ул
Бал кортларын да баккан.

**“А” хәрефе**

Анам телен өйрәнергә
Ярдәм итә Әлифба
Кайчандыр аны өйрәнгән
Анам белән атам да,
Әби белән бабам да.

Иң кадерле китабым
Әлифбам- син булырсың
Күңелемнең түрендә
Һәрчак балкып торырсың

Әлифбаның тышыннан
Һәр бала үзен таный
Иң кадерле китабым дип,
**Әлифбам,** сине саный.



Безнең Аю Серле йортка керә, һәм алар тату гына **бер гаилә** булып яши башлыйлар.
Әкиятебезнең ахырына җиттек. Серен ачсак та була.
Исегездә калды микән? Кемнәр шакыды Серле йортның ишеген?

**Балалар җавабы.**
**Ә**крен куян, Бака- Лап - Лоп, **Ин**ң – иң озын колаклы куян,
**Ф**ырт хәйләкәр төлке, **Б**үре, **А**ю.
Алар нинди хәрефләр тотканнар иде?
Балалар җавабы

Ә Л И Ф Б А

Укытучы. – Нигә бу сүз безгә шулкадәр кадерле?

Укучы. -- **Әлифба**- һәрбер кешене беренче башлап укырга, язарга, сөйләргә, уйларга өйрәтүче.Безнең әкият дусларыбыз да үзләренчә укый да, яза да, сыйләшә дә, уйлый да беләләр. Билгеле инде аларга да Урман әлифбасы ярдәмгә килгән. Рәхмәт, сиңа Әлифба!



## Әлифба бәйрәме

**Әлифба бәйрәме**- укучыларның ярты еллык эшенә йомгак ясау тантанасы ул. Балаларның барысы да укырга, язарга, матур итеп сөйләргә, әдәпле булырга, өлкәннәрне һәм кечеләрне ихтирам итәргә, коллектив белән дус яшәргә, ирешкән уңышларга шатланырга, ярдәмчел булырга өйрәнәләр.

Бәйрәм 2 өлештән тора. Беренче өлештә мультимедиа кулланып, "Тиремкәй" әкиятенә ияреп, тылсымлы әкият иленә сәяхәт итү.

Икенче өлештә балалар чыгышы. Сыйныф бүлмәсе бәйрәмчә бизәлә. Тактада "Рәхмәт сиңа, Әлифба!", "Сау бул, Әлифба!" дигән плакатлар, шарлар эленә.

### Барышы:

**Алып баручы:**

Көч безнең күнелгә
Җыр яме, җир яме.
Рәхим ит, түрдән уз-
Әлифба бәйрәме!

**Бала.**
Әлифба, әлифба беренче битеңне



Ачкан көн хәтердә зур бәйрәм шикелле
Иң якын дустыбыз булдың син гел безнең
Һәр хәреф елмаеп әйтте үз исемен.
Һәм алар бик матур сүзләргә әйләнде
Сүз төзеп укуы, кызыклы, күңелле!
Әлифба, әлифба, китәсең бит инде
Җыр итеп җырлыйбыз иң соңгы битеңне.

"Әлифба" җыры башкарыла.Р. Вәлиев сүзләре, М. Мухин көе.

Әлифба- иң якын дус!
Әлифба- иң яхшы китап!
Әлифба- иң якын җыр!
Әлифба- иң матур шигырь!

Хәрефләр тоткан укучылар чыгышы. Шигъри сәхифә.

**"Ә" хәрефе**

"Ә" хәрефе бик кадерле
Бар ул әти- әнидә
Бабай гына читтә кала
Бар ул хәтта әбидә.

**"Л" хәрефе**

"Л" дан башланган сүзләрне
Эзләдек без дәрестә
Ләйсән, Ләйлә,Ләмига
Төзеде дәфтәрләрдә.

**"И" хәрефе**

Ипи, икмәк- иң кадерле
Бу дөньяда һәркемгә
Икмәк булмаса өстәлдә
Яшәп булмый беркөн дә